# «ТУАР КӨНГӘ ЯКТЫ ЫШАНЫЧЫМ»
## Айрат Суфиянов
## иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә
*(өлкән сыйныф укучылары өчен)*

*Көй астында ике алып баручы чыга.*

**1нче алып баручы:**

Кара болыт күкне капласа да
Һәм иссә дә шомлы җилләр ярсып.
Бу тормышның һәрбер көне ямьле,
Бу тормышның һәр мизгеле тансык.

**2нче алып баручы:**

Туар көнгә якты ышанычым
Чыңлаганда горур бер җыр булып,
Дөньялыкка зур шәхесләр сорап,
Чиксезлеккә карыйм томырылып.

«*Туар көнгә якты ышанычым»*

**1нче алып баручы:** Хәерле көн, кадерле дуслар.

**2нче алып баручы:** «*...Шигърият – мәңгелек балачак. Шагыйрь исә ак сакаллы бала. Шуңа шагыйрь күңелендә «кыш булмый вә кар яумый». Картаймый, шагыйрь замана керен эченә җыймый, караймый, бала кебек күңеленә килгән уй-фикерне, нинди генә «куркыныч» булмасын, балачак эчкерсезлеге белән ярып сала. Бала да шагыйрь кебек пәйгамбәри заттан»*, - *дип яза Айдар Хәлим.*

**1нче алып баручы:** Бүгенге әдәби-музыкаль кичәбездә шигърият турында сүз алып барырбыз, ул Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь Айрат Суфиянов иҗатына багышлана.

**2нче алып баручы:** Айрат Тәлгать улы Суфиянов 1958 елның 26нчы мартында Башкортстан Республикасының Балтач районы Усман авылында туа. 1975 елда Нөркә урта мәктәбен, аннан соң Уфада энергетика техникумын тәмамлый. 1979-1980 елларда Самара шәһәрендә армия сафларында хезмәт үтә. 1981-1985 елларда Коми АССРда, 1985 елдан бирле гаиләсе белән Чаллы каласында яши. Хәзерге вакытта КамАЗның двигательләр заводында эшли.

**1нче алып баручы:** Шигъри җанлы, шигъри күңелле егет мәктәп елларыннан бирле шигырьләр яза. Беренче шигырьләре Башкортстан Республикасының Балтач районы газетасында 1983-1985 елларда басыла. Айрат Суфиянов – 2007 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Шагыйрь күңелен аңлар өчен түбәндәге шигырь юлларын ишетүдә җитә.

...Фил шикелле көчле булмасам да,
Бөтенләй үк хәлсез түгелмен...
Галәм кебек гади, тормыш кебек
Беркатлы да минем күңелем...

*«Күңел»*

**2нче алып баручы:**

...Хуш исләрен иснәп тугайларның,
Тургайларын тыңлап язның мин,
Җиргә, күккә, бөтен тереклеккә
Сөю юллап шигырь яздым мин.

Шул шигырьгә керттем урманнарның
Җил искәндә ярсып шаулавын.
Язмышымның горур югарылык
Һәм мәкерсез ирек даулавын.

*«Җан бәясе»*

**1нче алып баручы:** Җиргә, күккә, бөтен тереклеккә, сөю юллап язган шигырь юллары шагыйрьнең күңелендә генә калмый, ак дәфтәр битләренә дә төшә. Алай гына түгел беренче шигъри җыентык «Кылычлы җил» (2006) исеме белән Татарстан китап нәшриятында басылып ук чыга.

Дулкын бәрә, күзгә дулкын аша
Үтеп керә кояш яктысы.
Җанда шигырь, шигырьдә җан яши,
Бер тамырдан алар, ахрысы.

*«Өлешемә тигән көмешем бу»*

**2нче алып баручы:** Шагыйрьлек ул – маңгай һәм дә күңел күзең күрмәгәнне, йөрәгең, җаның тойганны беркемне дә кабатламый, үзең генә әйтә белгәнчә шигъри сүзгә төреп аңлатып бирә алу осталыгына ия булудыр. Алай гынамы, шигъри әйтелеш, сүзләрдән үрелгән гаҗәеп челтәр шулкадәр матур, тылсымлы, илаһи тәэсирле булырга тиеш, йөз елдан соң да меңнәрне сискәндереп уятырлык, сокландырып елатырлык, назлап юатырлык, кыскасы, таң калдырырлык...

*Укучылар чыгышы.*

**1нче укучы:**

Язларда да яфрак койганым бар,
Яфрак ярганым бар көзләрдә.

Үлә-үлә кабат туганым бар,
Ялкынланып, янып туңганым бар,
Теләктәшлек юллап күзләргә.

Көлә-көлә елаганым да бар,
Елый-елый көлгән чагым да.
Бу дөньяның бөтен каршылыгы
Холкым булып миндә чагыла.

Көчле чакта хәлсез булганым бар,
Хәлсез чакта көчле булганым.
Мин дөньяга тыныч ярсу белән
Каршылыклы уйдан туганмын.

Каршылыкта минем акыл төшем,
Каршылыктан туган тереклек.
Акта яши, яши карада да
Сулыш булып тиңсез бөеклек...

*«Каршылык»*

**2нче укучы:**

Киртә түгел ерак чакрымнар да,
Мин ишетәм йөрәк кагышыңны.
Көтмәсәм дә инде кавышуны,
Тоеп яшим бөтен сагышыңны.

Толымнарың җилдә чайкалдырып,
Таң калдырып бөтен тирә-юньне
Эзлә, бәгърем, эзлә Ләйлә булып
Сине сагынучы мин Мәҗнүнне.

Күрәм, күрәм таң нурлары аша
Син кагылган чәчәк тирбәлгәнен.
Күзләреңә минем күзләр белән
Күрәсеңме аның төбәлгәнен?!

Йөрәгемнән чыккан сөю хисе
Синең белән барыбер күрешәчәк.
Ишеттеңме, сөйли шул турыда,
Хуш ис сибеп, син кагылган чәчәк.

*«Сөю хисе»*

**3нче укучы:**

Хыял – бөек... Йолдызларга аша,
Тоташтыра җирне күк белән.
Иксез-чиксез киңлекләрне коча

Һәм тантана итә: «Күп беләм».

Хыял – бөек... Аның көченә дә,
Могҗизасына да ышанам.
Салкын кышта алланыплар пешкән
Алма булып төшә җиһаннар.

Хыял – бөек... Хыял канатлы да,
Җилдән җитез, һәрчак алда ул.
Көзне – кышка, кышны язга ялгап,
Тургай булып сайрый ала ул...

Хыял – бөек... Әллә хыял булып
Кошлар сайрый, таңнар атамы?..
Чынбарлыкка ашмас хыялларның
Кай тарафта икән Ватаны?

*«Хыял – бөек»*

**1нче алып баручы:** Киләчәк гасырлар пәрдәсен ачып карау берәүнең дә кодрәтеннән килми, билгеле, ә менә бүгенге көндә бик тә бай һәм борынгы булган татар шигърияте бакчасында шагыйрь Айрат Суфияновның күңел гөлләре аерым бер ямьле, серле түтәл хасил итеп тирбәләләр.

**2нче алып баручы:**

...Чишмәләрдә авыл җаны,
Чишмәләр чыңлап торсын,
Чишмәләрдән илһам алып,
Иң моңлы җырлар тусын,

*«Чишмәләрдә авыл җаны»*

*Җыр башкарыла.*

**Җыр:**

Ярсуларым булып кар сулары,
Агыла да һаман агыла.
Кар сулары ташып аккан кебек,
Ашкынам мин туган ягыма.

Яз илчесе умырзая калка,
Тишеп чыга карны эретеп.
Ник гомерләр читтә саргая соң?
Күңелләрне сусыз гөл итеп.

Сагынышып туган як язына,
Сайрый-сайрый кошлар кайталар.

Ак тылсымга чумып алмагачлар,
Бакчаларда чәчәк аталар.

Ярсуларым булып кар сулары,
Елгаларга агып төшәләр.
Киткән түгел, кайткан кош авазын,
Якын күрә бездә чишмәләр.

*«Ашкынам мин туган ягыма»*
*(Айрат Суфиянов сүз., Рубис Зарипов көе)*

**2нче алып баручы:** Адәм балалары шулай яратылган булса кирәк. Бәхет эзләп читкә, туган якларыннан еракка китә, аны һәрдаим яратып, сагынып яши. «Сагыну» дип исемләнгән шигырь моның бер дәлиле.

Бераз гына миңа үпкәләпме,
Бераз гына әллә сагынып,
Чит җирләрнең бар хуш исен күмеп,
Туган яктан,
Кояш нурларында чагылып,
Ялантәпи чапкан язгы шаян
Җилнең ялларына тагылып,
Сирен исме килә агылып.
Әнкәй әйткән ягымлы сүз булып
Иреннәрдә кала ягылып.

*«Сагыну»*

**1нче алып баручы:** Айрат Суфияновның һәрбер шигыре – йә матур табыш, йә серле ачыш, йә хыялый очыштыр. Өстәвенә, алар нindидер әрнүле аһәң-моң белән дә төрелгән. Искиткеч әсәрләр!

Моңлансам да, моңланыгыз, димим,
Һәркем яши җирдә үзенчә.
...Сискәнәм мин яшь бер гомер кебек
Яшел килеш яфрак өзелсә.

*«Шагыйрьлегем гүзәл балачак»*

**2 нче алып баручы:** Шагыйрьнең иҗатын каләмдәшләре дә югары бәяли. Язучы Айдар Хәлим түбәндәгечә яза:

«*...Шагыйрь булып бишектән төшкән, беренче шигъри аһәңнәреннән башлап, бүгенге көнгә кадәр дистәләгән шигырь язып, замандашларын гына түгел, чыкны да, үлән кыягын да сискәндереп килгән затларның берсен тәкъдим итәчәкмен.*

*...Айрат Суфиянов характеры, масштабы ягыннан лиро-эпик шагыйрь. Ул, тирән фәлсәфи лирик шигырьләр белән беррәттән, зур эпик әсәрләр язарга да сәләтле. Һичшиксез, аның белән шигъриятебезгә Тукай-*

*Такташ-Туфан традицияләрен арытаба үстерәчәк яңа шагыйрь килде. Никадәр милләткүләм куаныч: китмәскә килде...»*

**1нче алып баручы:** Шагыйрә Әлфия Ситдыйкова шигъри юллар багышлый:

«Сызлап актарылып, үксез йөрәк булып... »
Яшәр өчен түгел, яшьнәр өчен килгән.
Шагыйрь сорау ала: «Бөтен дөнья нигә
Каршылыклы?!» – диеп, саташулы илдән.

«Әллә яшим җирдә, әллә сүнеп барам...»
Беләм, шагыйрь, тирән синең йөрәк яраң.
Илнең фаҗигасен карашыңа салып,
Язасың син шигырь, кипмәсен лә караң.

Каурый каләмеңдә караң беткән чакта,
Язарсың син җырың, йөрәк каның белән.
Әрнеп каһәрләргә тумагансың җиргә,
Яшен кебек яшьнәп яшәр өчен килгән.

*«Сызлап актарылып, үксез йөрәк булып... »*

**2нче алып баручы:** Ә шагыйрә Сирень Якупова болай яза:

*«...Бер уйласаң шагыйрьнең «колаккача авыз ерылган» мәле дә, дөньясының «кайберләрдән шашып йомарланган» чагы да һәрберебезгә үтә дә таныш халәт. Ә менә тәннең-җанның шундый һәрбер халәтен, шатлык-газапларны, сөю-нәфрәтне, туу белән үлемне, бер сүз белән әйткәндә, тормышны шигырь итү талантын Ходай бик сирәкләргә генә бирә. Айрат Суфиянов шундый бәхетлеләрнең берсе...»*

**1нче алып баручы:** Тормыш ул диңгездәй. Диңгезнең агымына эләгеп, язмыш сине кая ташлый. Менә шул көчле, ярсу дулкын чыгарып ташлаган җирлектә үзең ничек яшисең, ничек эшләргә тырышасың – анысы инде кешедән, һәркемнең үзеннән тора.

Айрат Суфияновка җирлекнең ныклысын, ышанычлысын телим. Беркайчанда сынатмас, сыгылмас, дип ышанып калам.

**2нче алып баручы:**

...Якты киләчәк ул кемгә кирәк,
Арып-талып нигә көтәргә?
Без кешечә бүген яшәмәсәк,
Яши алмас идек иртәгә.

**1нче алып баручы:**

Киләчәктә инде без булмабыз,
Башкалармы бездәй алданыр?

Мин тагын да алданырга риза,
Бәхет әле, бәлки алдадыр...

*«Якты киләчәк ул кемгә кирәк»*

**2нче алып баручы:** Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь, Айрат Суфияновка, һәр туар көнгә якты ышанычын белдереп, бәхетле гомер итәргә, бик күп еллар шигърият юлында очраган татлы мизгелләрне кичерергә насыйп булсын.

**1нче алып баручы:** Ә безгә Айрат Тәлгать улы Суфияновның талантына сокланып, җан сусавын басып, шигырьләрен укырга гына кала.

## Файдаланылган әдәбият


Зарипов, Р. Җырлап ачыла күңел: җырлар / Р.Зарипов. – Яр Чаллы: ООО «Диамант», 2016. – Б. 18.

Ситдыйкова, Ә. Кадерле бүләк: котлаулар / Ә. Ситдыйкова. – Казан: «Идел-Пресс», 2013. – Б. 11.

Суфиянов, А. Кылычлы җил: шигырьләр / А. Суфиянов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 207 бит.

Хәлим, А. Ак биләүләр нуры: [шагыйрь иҗатын бәяләп] / А.Хәлим // Шәһри Чаллы. – 2011. – 12 август. – Б. 19.

Якупова, С. Уяналар җанда ак хисләр...: [шагыйрьгә 50 яшь тулу уңае белән] / С. Якупова // Шәһри Чаллы. – 2008. – 26 март. – Б. 14.